Республика Татарстан
Муртыш-Тамакское
сельское поселение Сармановского
муниципального района

ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

Татарстан Республикасы
Сарман
муниципаль районының
Мортыштамак
авыл җирлеге

Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

Телефон: (85559) 4-52-05, факс: (85559) 4-52-05, E-mail:Murtam.Sar@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

11.11.2020 №11

Мортыштамак авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 23 мартындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Мортыштамак авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Мортыштамак авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 23 мартындагы 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан салым аванс белән, узган хисап чорыннан агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процентының тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә түләнә. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнә».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.«Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылган көннән бер айдан да иртәрәк түгел».

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мортыштамак авыл җирлеге
Советы Рәисе: И.Н.Хадиуллин